**МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

14.05.2015 № 308

г.Казань

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2015 елның 24 июлендә теркәлде, № 2807

Татарстан Республикасы Хезмәт,
халыкны эш белән тәэмин итү
һәм социаль яклау министрлыгы
һәм Россия Федерациясе гражданины арасында,
укып бетергәч, Татарстан Республикасының
дәүләт гражданлык хезмәтен
Татарстан Республикасы Хезмәт,
халыкны эш белән тәэмин итү
һәм социаль яклау министрлыгында
башкару йөкләмәсе белән, максатлы укыту
турында килешү төзүгә
конкурс процедураларын уздыру
методикасын раслау хакында

“Россия Федерациясендә дәүләт гражданлык хезмәте турында” 2004 елның 27 июлендәге № 79-ФЗ Федераль законга, Россия Федерациясе Президентының “Максатлы укыту турындагы килешүләр буенча федераль дәүләт гражданлык хезмәте өчен кадрлар әзерләү хакында” 2009 елның 21 декабрендәге № 1456 Указына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Федераль дәүләт органы һәм Россия Федерациясе гражданины арасында, укып бетергәч, федераль дәүләт гражданлык хезмәтен башкару йөкләмәсе белән, максатлы укыту турында типовой килешүне раслау хакында һәм шундый килешүләр төзегән гражданнарга өстәмә түләү бирү һәм аның күләме хакында” 2010 елның 21 июнендәге № 469 карарына һәм “Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәте турында” 2003 елның 16 гыйнварындагы № 3-ТРЗ Татарстан Республикасы законына туры китереп боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы һәм Россия Федерациясе гражданины арасында, укып бетергәч, Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәтен Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында башкару йөкләмәсе белән, максатлы укыту турында килешү төзүгә конкурс процедураларын уздыруның кушымта итеп бирелүче методикасын расларга.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы һәм Россия Федерациясе гражданины арасында, укып бетергәч, Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәтен Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында башкару йөкләмәсе белән, максатлы укыту турында килешү төзүгә конкурсны игълан итү һәм уздыру турында карар Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы боерыгы белән рәсмиләштерелә дип билгеләргә.

3. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары М.Р. Гафаровка йөкләргә.

**Министр** **Э.Ә. Зарипова**

Татарстан Республикасы Хезмәт,
халыкны эш белән тәэмин итү һәм
социаль яклау министрлыгының
2015 елның 14 маендагы № 308 боерыгына
кушымта

**Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы һәм Россия Федерациясе гражданины арасында, укып бетергәч, Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәтен Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында башкару йөкләмәсе белән, максатлы укыту турында килешү төзүгә конкурс процедураларын уздыру методикасы**

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы һәм Россия Федерациясе гражданины арасында, укып бетергәч, Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәтен Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында башкару йөкләмәсе белән, максатлы укыту турында килешү төзүгә конкурс процедураларын уздыру методикасы (алга таба тиңдәшле рәвештә – Методика, Министрлык, гражданлык хезмәте) укыту өчен Татарстан Республикасының дәүләт органы һәм Россия Федерациясе гражданины арасында, укыту тәмамланганнан соң билгеле бер срок дәвамында Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәтен башкару йөкләмәсе белән, килешү төзү тәртибе турындагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 08.08.2011ел, № 640 карары белән расланган нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) туры китереп төзелде һәм югары белем бирү федераль дәүләт мәгариф оешмаларында яки тиешле мәгариф программалары буенча дәүләт аккредитациясенә ия һөнәри мәгариф оешмаларында (алга таба – мәгариф оешмасы) укучы Россия Федерациясе гражданнарын, укып бетергәч, Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәтен Министрлыкта башкару йөкләмәсе белән, Министрлык һәм Россия Федерациясе гражданины арасында максатлы укыту турында алар белән килешү төзү өчен сайлап алу буенча конкурс (алга таба тиңдәшле рәвештә – максатлы укыту турында килешү, Конкурс) оештыруны һәм аны уздыруның тәртибен билгели.

2. Министрлык һәм Россия Федерациясе гражданины (алга таба – дәгъва кылучы) арасында, укып бетергәч, Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәтен Министрлыкта башкару йөкләмәсе белән, максатлы укыту турында килешү төзүгә конкурсны игълан итү һәм уздыру турында карар Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры (алга таба – Министр) тарафыннан кабул ителә һәм Министрлык боерыгы белән рәсмиләштерелә.

3. Конкурс Министрлыкның дәүләт гражданлык хезмәте вакантлы вазыйфасын биләүгә “Россия Федерациясендә дәүләт гражданлык хезмәте турында” 2004 елның 27 июлендәге № 79-ФЗ Федераль законның (алга таба – № 79-ФЗ

Федераль закон) 22 статьясына туры китереп оештырылган Конкурс комиссиясе (алга таба – Конкурс комиссиясе) тарафыннан уздырыла.

4. Конкурс комиссиясе утырыш уздыра һәм, гражданлык хезмәте вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру өчен Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән тәртиптә, максатлы укыту турында килешү төзү хакында карар кабул итә.

5. Конкурста катнашырга теләк белдергән дәгъва кылучы Министрлыкка түбәндәгеләрне тапшыра:

а) шәхси гариза;

б) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2005 елның 26 маендагы № 667-р әмере белән расланган форма буенча үз кулы белән тутырылган һәм имзаланган, үзенең фотосурәте өстәлгән анкета;

в) паспорт күчермәсе (паспорт, Конкурска килгәч, шәхсән күрсәтелә);

г) хезмәт кенәгәсе күчермәсе яки гражданинның эшләгәнен (хезмәт иткәнен) раслаучы бүтән документлар (эшләү (хезмәт итү) элегрәк башкарылмаган очраклардан гайре);

д) гражданинда гражданлык хезмәтенә керергә һәм аны башкарырга комачаулый торган авыруның юклыгы турында медицина учреждениесе йомгаклау нәтиҗәсе;

е) гражданинның мәгариф оешмасында көндезге уку формасында федераль бюджетның бюджет ассигнованиеләре хисабыннан югары яки урта һөнәри белемне беренче тапкыр алуын раслаучы, шулай ук, һөнәрне, белгечлекне яки хәзерлек юнәлешен күрсәтеп, ул үзләштерә торган мәгариф программасы турында, укыту планы нигезендә гражданинның арадаш аттестацияләр үтүе нәтиҗәләре турында, аның мәгариф оешмасы уставы һәм эчке тәртип кагыйдәләре белән күздә тотылган бурычларын ничек үтәве турында мәгълүматны эченә алган мәгариф оешмасы белешмәсе.

Әлеге документлар, Конкурс уздырылу турында белдерү урнаштырылган көннән башлап 21 календарь көне эчендә, дәгъва кылучы тарафыннан Министрлыкка тапшырыла.

6. Документларны, мөһим сәбәпсез, вакытында тапшырмау, аларны тулы булмаган күләмдә яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшыру дәгъва кылучыга Конкурста катнашырга мөмкинлек бирүдән баш тартуга нигез булып тора.

7. Конкурс ике этапта уздырыла.

8. Беренче этапта Министрлыкның дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге:

8.1. Конкурс уздыру турында белдерү әзерли һәм, Конкурсның 2 нче этабы уза торган көнгә кадәр 45 календарь көненнән соңга калмыйча, бер яки берничә вакытлы матбугат басмасына һәм Министрлыкның "Интернет" челтәрендәге рәсми сайтына урнаштыра. Белдерүдә дәүләт гражданлык хезмәтенең укуларын тәмалаганнан соң гражданнар биләргә тиешле вазыйфа категорияләре һәм төркемнәре; бу вазыйфаларга квалификация таләпләре (һөнәри белем дәрәҗәсенә, һөнәри гыйлем һәм вазыйфаи бурычлары үтәү өчен кирәкле күнекмәләргә таләпләр); Методиканың 5 пунктына туры китереп, Конкурска тапшырылучы документлар исемлеге; аларны кабул итүнең урыны һәм вакыты; әлеге документлар шул вакыт тәмамланганчыга кадәр кабул ителә торган срок; Конкурс уздыру көне,

урыны һәм тәртибе; тест үткәрү өчен сораулар исемлеге күрсәтелә, шулай ук башка мәгълүматлы материаллар да кирәргә мөмкин;

8.2. гражданнарның гаризаларын теркәү журналында аларны Конкурста катнашу өчен терки;

8.3. Методиканың 5 пунктында күрсәтелгән кергән документларны, аларны кабул итү тәмамланган көннән башлап, 7 календарь көне дәвамында тикшерә;

8.4. Конкурсның 2 нче этабы уздырылганга кадәр 15 календарь көненнән дә соңга калмыйча, хәбәр итә:

Конкурста катнашу рөхсәт ителгән дәгъва кылучыларга – Конкурсның 2 нче этабын уздыруның көне, урыны һәм вакыты турында, тиешле мәгълүматны Министрлыкның "Интернет" челтәрендәге рәсми сайтына урнаштыру юлы белән;

Конкурста катнашу рөхсәт ителмәгән дәгъва кылучыларга – Конкурста катнашырга рөхсәт итүдән баш тартуның сәбәпләре турында, почта аша язмача.

Конкурс уздырганда, дәгъва кылучыларга, Россия Федерациясе Конституциясе һәм Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә, хокукларының тигезлеге гарантияләнә.

9. Конкурсның 2 нче этабын уздыруның көне, урыны һәм вакыты турында карар, дәгъва кылучылар тапшырган мәгълүматларны дөреслеген тикшергәннән соң, Министр тарафыннан кабул ителә.

10. Конкурсның 2 нче этабында Конкурс комиссиясе дәгъва кылучының теоретик белемнәрен һәм шәхси сыйфатларын бәяли һәм максатлы укыту турында килешү төзү хакында карар кабул итә.

11. Конкурста катнашу рөхсәт ителгән дәгъва кылучыларның теоретик белемнәрен һәм шәхси сыйфатларын бәяләү өчен, Россия Федерациясе Президентының “Максатлы укыту турындагы килешүләр буенча федераль дәүләт гражданлык хезмәте өчен кадрлар әзерләү хакында” 2009 елның 21 декабрендәге № 1456 Указы белән билгеләнгән, шул исәптән тест һәм шәхсән әңгәмә үткәрүне күздә тоткан Конкурс процедуралары кулланыла.

12. Конкурста катнашу рөхсәт ителгән дәгъва кылучыларның теоретик белемнәрен һәм шәхси сыйфатларын бәяләү түбәндәге критерийлар буенча башкарыла: теоретик белемнәрнең дәрәҗәсе, теоретик белемнәрне гамәли биремнәр үтәгәндә куллана белү, җавапны мантыйкка туры китереп төзү, грамоталылык һәм сөйләм культурасы.

13. Дәгъва кылучыларга тест уздыру Россия Федерациясе Конституциясе һәм Татарстан Республикасы Конституциясе нигезләмәләрен, дәүләт гражданлык хезмәте турындагы законнарны, Конкурска игълан ителгән гражданлык хезмәте вазыйфасының вазыйфаи регламенты нигезләмәләрен, шул исәптән квалификация таләпләрен, Министрлык эшчәнлегенең билгеләнгән өлкәсендәге бүтән (аларны белү, укуын тәмамлагач, гражданин белергә тиешле гражданлык хезмәте вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычларны үтәү өчен зарур булган) норматив хокукый актларны белүгә теория сораулары исемлеге (алга таба – исемлек) буенча башкарыла. Әлеге исемлеккә кертелгән сорауларның саны 100дән ким булмаска тиеш. Сорауларның иң зур саны чикләнмәгән. Һәр сорауга җавапларның өчтән ким булмаган варианты күздә тотыла, шуларның берсе дөрес була.

Дәгъва кылучыларга тест уздыру исемлектән очраклы рәвештә сайлап алынган 10 сорауга җавап бирүдән гыйбарәт. Дәгъва кылучыларның барысына да

тест сорауларына җавап бирү өчен күп дигәндә 10 минут вакыт бирелә. Дәгъва кылучы тест сорауларына җавапны Конкурс комиссиясенең кимендә ике әгъзасы алдында бирә. Тест уздыру барышында махсус, белешмә әдәбияттан, язмалардан, кәрәзле элемтә чараларыннан, мәгълүматны саклау һәм тапшыру чараларыннан файдалану, дәгъва кылучыларның тест уза торган аудиториядән чыгуы рөхсәт ителми.

Конкурс комиссиясе бәяне дөрес җаваплар санына карап куя.

Дөрес җаваплар саны тест нәтиҗәләре буенча баллар суммасын билгели (һәр дөрес җавап 1 баллны тәшкил итә).

Дәгъва кылучы 7дән кимрәк балл җыйган очракта, ул тестны узмаган дип санала һәм шәхсән әңгәмәгә кертелми.

14. Тестны уңышлы узган дәгъва кылучы белән шәхсән әңгәмәне Конкурс комиссиясе әгъзалары үткәрә.

Шәхсән әңгәмә дәгъва кылучы белән ирекле гәпләшү рәвешендә үткәрелә, аның барышында Конкурс комиссиясе әгъзалары сораулар бирә. Шәхсән әңгәмә вакытында Конкурс комиссиясе әгъзалары дәгъва кылучының рус телен белүен һәм сөйләм культурасын, мәгариф учреждениесендәге өлгереш дәрәҗәсен, фәнни мәкаләләре булуны, мәгариф учреждениеләре уздыра торган фәнни конференцияләрдә, олимпиадаларда һәм башка чараларда катнашуын, хакимиятнең дәүләт органнарында практика узуын һәм практика җитәкчесенең уңай бәяләмәсе булуны, шулай ук Министрлыкта эшләү теләген нигезләвен исәпкә ала.

15. Шәхсән әңгәмә нәтиҗәләре буенча Конкурс комиссиясенең һәр әгъзасы дәгъва кылучыга 0дән 10га кадәр балл бирә. Дәгъва кылучыга Конкурс комиссиясенең барлык әгъзалары куйган баллар тест билгесе белән кушыла.

16. Конкурсның җиңүчесе дип, тест һәм шәхсән әңгәмә нәтиҗәләре буенча иң күп балл җыйган дәгъва кылучы танылa. Баллар саны тигез булганда, Конкурс комиссиясе карары, ачык тавыш биреп, Конкурс комиссиясе утырышында катнашкан әгъзаларның күпчелек тавышы белән, һәр дәгъва кылучы буенча аерым кабул ителә. Тавыш биргәндә, Конкурс комиссиясе әгъзаларының фикере "риза" яки "каршы" дигән сүзләр белән чагылдырыла. Тавышлар саны тигез булганда, Конкурс комиссиясе рәисенең тавышы хәлиткеч була. Карар дәгъва кылучы югында кабул ителә.

17. Конкурста катнашкан гражданнарга нәтиҗәләр турында Конкурс тәмамланган көннән башлап бер ай эчендә язмача хәбәр ителә.

18. Әгәр Конкурс уздыру нәтиҗәсендә җиңүче ачыкланмаса, шулай ук Конкурста катнашу өчен икедән кимрәк дәгъва кылучы теркәлгән очракта, Конкурс комиссиясе Конкурсны узмаган дип таный.

19. Конкурста катнашуга кертелмәгән дәгъва кылучыларның һәм Конкурста катнашкан, ләкин анда җиңмәгән дәгъва кылучыларның документлары, язмача гариза буенча, Конкурс тәмамланган көннән алып өч ел эчендә, аларга кире кайтарылырга мөмкин. Бу срок тәмамланганчы, документлар Министрлыкның дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегендә саклана, аннан соң юк ителә.

20. Конкурста катнашуга дәгъва кылучы гражданнар, Россия Федерациясе законына туры китереп, Конкурс комиссиясенең Конкурста катнашуга кертмәү турындагы карарына карата шикаять белдерергә хокуклы.

Конкурста катнашкан гражданнар, Россия Федерациясе законына туры китереп, Конкурс комиссиясе карарына карата шикаять белдерергә хокуклы.